| ГЛАВА НИЖНЕЧЕКУРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ДРОЖЖАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЧҮПРӘЛЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТҮБӘН ЧӘКЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ |
|---|---|

с.Нижнее Чекурское

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18 ноябрь 2021 ел №25

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Югары Чәке авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Түбән Чәке авыл җирлеге Уставының 12.1статьясы, Түбән Чәке авыл җирлеге Советының 10.10.2019 ел, № 52/1 карары (15.11.2019 ел, № 54/2 редакциясендә) белән расланган «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Түбән Чәке авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе» нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Түбән Чәке авыл җирлегенең Югары Чәке торак пунктында гражданнар җыенын 2021 елның 30 ноябренә 09.00 сәгатьтә Татарстан Республикасы, Чүпрәле районы, Түбән Чәке авылы, Совет урамы, 11 йорт адресы буенча гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча билгеләргә.

2. Гражданнар җыенында түбәндәге мәсьәләне расларга:

"2022 елда Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Түбән Чәке авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 300 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия түбәндәге эшләрне башкару буенча мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә килешәсезме:

- Югары Чәке авылында Дзержинск, Ленин урамындагы урам-юл челтәрләрен ремонтлау

«ӘЙЕ» «ЮК»».

3. Әлеге карар рәсми бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) тиеш.

Түбән Чәке авыл җирлеге башлыгы: О.Б.Албутов